Ф.Р. Сибгаева

Казан федераль университеты, Казан

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫННАН ҺӘМ Ф.С. САФИУЛЛИНА ЭШЧӘНЛЕГЕ

В данной статье рассматривается история изучения татарской фразеологии и деятельность Ф.С. Сафиуллиной в этой области. Анализируются научные труды, словари, посвященные изучению фразеологии в разные годы XIX-XXI вв. Приводится подробный анализ словаря Ф.С. Сафиуллиной «Татарско-русский фразеологический словарь».

In this article the history of studying of the Tatar phraseology and F.S.Safiullina's activity in this area is considered. Scientific works, the dictionaries devoted to studying of phraseology in different years of the XIX-XXI centuries are analyzed. The detailed analysis of the dictionary is provided F.S. Safiullina «The Tatar-Russian phraseological dictionary».

Халыкның тормыш тәҗрибәсе, гасырлар буе туплаган акылы, күзәтүләре аның иҗатында чагылыш тапкан. Халык авыз иҗаты әсәрләре үз составларында телебезнең лексик байлыгын китереп җиткергәннәр. Халык авыз иҗатының бер үрнәге буларак фразеологизмнар борынгы чорларда ук барлыкка килгәннәр һәм халкыбызның образлы фикер йөртүгә осталыгын күрсәтеп торалар. Алар күчерелмә мәгънәлелеккә, экспрессивлыкка, стилистик чараларга бай.

Бербөтен мәгънә белдерә торган тотрыклы сүзтезмәләргә фразеологик әйтелмәләр дибез. Аларның барлыкка килүе, кешеләрдә абстракт, метафорик уйлау сәләте үсү белән бәйләнгән, ягъни ирекле сүзтезмәләрнең фразеологик сүзтезмәгә әйләнүе нигезендә күчерелмә мәгънәләрнең үсеше ята. Фразеологизмнар әйберләрне, күренешләрне бер-берләренә охшату, чагыштыруга нигезләнгәннәр. Мәсәлән, *ачы тел* дигән фразеологик берәмлек берәр төрле *ачы ризык* белән чагыштырудан килеп чыккан. Болар арасында уртаклык һәм охшашлык булып тәмсезлек, ачы, тозлылык тора. Фразеологизм составындагы сүзләрнең берсе һәрвакыт күчерелмә мәгънәдә була [2: 5]. Фразеологик әйтелмә телдә әзер килеш сакланган хәлдә, сөйләмгә

урнаштырыла. Алар семантик яктан бөтен булалар, ягъни бөтен сүзтезмә нинди дә булса бер читләтелгән төшенчәгә кайтып кала [3: 3]. Аларның бу үзенчәлекләре компонентларның даими һәм береккән булуын барлыкка китерә.

Татар теле фразеологизмнарының бик ерак тарихи тамыры бар. Язма әдәби әсәрләр барлыкка килгәнче үк халык бик күп фразеологик әйтелмәләр иҗат иткән. Бу исә ата-бабаларыбызның борынгы заманнарда ук образлы фикер йөртүгә осталыкларын, күчерелмә мәгънәлелеккә, экспрессивлыкка, стилистик чараларга нык игътибар иткәнлекләрен раслый.

Татар фразеологиясенә игътибар итү, нигездә, XIX гасырда башлана. Фразеологик берәмлекләргә беренче фәнни аңлатманы Каюм Насыйри бирә. Бу төр әйтелмәләрне ул үзләренең төп мәгънәләреннән күчерелгән, яшерен (читләтелгән) мәгънәле сүзләр (кәлимәләр) дип атый. Г.Алпаров тарафыннан төзелгән җыентыкның «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма» бүлегендә читләтеп әйтелгән сүзләр (кинаялар), тапкыр җаваплар, каргышлар һәм алкышлар кебек баш астында телебездә киң таралган фразеологик әйтелмәләр байтак бирелгән.

Кайбер татар галимнәре фразеологик әйтелмәләрнең төзелеш тотрыклылыгы ягыннан һәм мәгънәләре белән бердәй түгеллеген истә тотып, түбәндәгечә фикер йөртәләр: бертөрлесе – урнашкан мәгънәләрен саклаган хәлдә, үзләренең стандартлашкан төзелешләрен үзгәртүне һич тә күтәрмиләр, телдә шул килеш һәм күчерелмә мәгънәдә генә кулланылалар. Ә икенчеләрендә составындагы аерым сүзләре үзләренең туры мәгънәләрен саклаган хәлдә күпмедер стуктур яктан үзгәрә алалар. Шуңа нигезләнеп, мәсәлән, И.Рамазанов фразеологияне икегә бүлә: 1) идиомалар; 2) фразеологик әйтелмәләр [3: 139]. Идиомалар – эчтәлекләре һәм формаль төзелешләре ягыннан нигездә һәрвакыт бер үк төрдә саклана торган фразалар (теңкәгә тию, төпсез көймәгә утырту, коты чыга, ләктә сугу һ.б.). Аларда сүзләр күчерелмә мәгънәдә булалар (колак кагу, сай йөзү, таштан җүкә сую). Һәрбер телнең үзенә генә хас идиомалары була һәм гадәттә алар сүзгә-сүз тәрҗемә ителмиләр.

Фразеологик берәмлекләрдә дә күпмәгънәлелек (полисемия) күзәтелә. Г.Ахунҗанов *баш күтәрү* фразеологизмының 11 мәгънәсен китерә: 1) эштән аерылып тору; 2) йокыдан тору; 3) чирдән соң торып йөри башлау; 4) ешлек, буйсынганлык хәленнән аерылу; 5) һавалану, тәкәбберләнү; 6) килешмәвеңне белдерү, каршы чыгу; 7) сыйнфый мәнфәгатьләрне яклау өчен, изүче сыйныфларга каршы массовой кораллы чыгыш ясау; 8) төрле каршы көчләр турында: активлашу, җанлылык күрсәтә башлау, күтәрелеп чыгу; 9) хисләр, уйлар турында: җанлану, көчәю; 10) искергән мәгънә: барлыкка килү, дөньяга, мәйданга чыгу; 11) үсемлек турында: үсеп чыгу [1: 46-48].

Фразеологизмнар, кагыйдә буларак, телнең үз байлыгы нигезендә барлыкка киләләр. Ләкин халыклар, телләр арасында бәйләнеш, тәрҗемәләштерү процессында фразеологизмнар да бер телдән икенче телгә күчәргә, калькалаштырылырга мөмкин. Мәсәлән, татар теленә рус теленнән түбәндәгеләр кергән: *дамоклов меч – дамокл кылычы; делать из мухи слона – чебеннән фил ясау; в семье не без урода – семья имгәксез булмый; кот в сапогах – итекле мәче; другого поля ягода – бүтән алан җимеше* [3: 75].

Фразеологизмнарны сүзләрне өйрәнгән кебек үк өйрәнәләр, чөнки алар да, телнең үзенчәлекле атау берәмлекләре буларак, төшенчәләрне белдерәләр. Фразеологизмнарны төп мәгънәләре буенча өч типка бүләргә була: 1) мәгънәләре атау характерында ирекле була *(пәйгамбәр тырнагы);* 2) башка сүзләргә бәйләнеше фразеологик бәйле була *(җан-фәрманга чабу)*; 3) синтаксик бәйле мәгънәләр була һәм ул мәгънәләр теге яки бу җөмлә кисәге (хәбәр) функциясендә генә реальләшә *(акча тора, ак сакаллы карт булыр идең, үзеңә дошман түгелсең, бәласеннән башаяк, син күр дә мин күр, акмаса да тама; акча җимеше түгел, бакча җимеше).*

Г. Ахунҗанов татар тел белемендә фразеологизмнарны идиома дип атарга тәкъдим итә һәм аңа түбәндәге билгеләмәне бирә: идиома – сүзлек берәмлеге сыйфатында теркәлә торган, кимендә ике сүзле һәм специфик мәгънәле тотрыклы әйләнмә. Галим «фразеология» сүзе урынына бу фәнне идиоматика дип атарга тәкъдим итә һәм идиомаларның 12 төрен күрсәтә [1: 6].

Татар фразеологиясе өлкәсендә 60-90 нчы елларда шактый күп эшләр башкарыла: 1957 елда Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова, Л. Җәләй төзегән «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дигән сүзлек дөнья күрә. Анда 6000 берәмлек теркәлгән. Саф лексик фразеологиядән башка халык авыз иҗатының махсус бер жанрына керә торган мәкальләр һәм әйтемнәр дә урын алган. 1959 елда, төрки тел белемендә беренче булып, «Русча-татарча фразеологик сүзлек» басылып чыга (Н. Б.Борһанова һәм Л.Т. Мәхмүтова). Турыдан-туры фразеологик сүзлек дип аталмаса да, аерым галимнәр тарафыннан фразеологизмнарга кертелә торган мәкальләр төрки филологиясендә тиңе булмаган зур бер хезмәткә – Н. Исәнбәтнең 3 томлык «Татар халык мәкальләре»нә тупланып бирелгән. Тематик яктан күп санлы төркемнәргә бүленеп бирелгән бу җәүһәрләр тел һәм халык тарихы өчен әйтеп бетергесез кыйммәтле һәм бай чыганак булып тора. 1980 елда Л.К. Бәйрәмова төзегән «Русско-татарский фразеологический словарь В.И.Ленина» исемле сүзлек басыла. 1972 елда Г. Ахунҗанов татар фразеологиясе буенча «Татар теленең идиомалары» монографиясен бастыра. 1982 елда Г.Х. Әхәтовның «Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге» дөнья күрә.

Татарстанның халык язучысы һәм зур галим Нәкый Исәнбәтнең 1989-1990 нчы елларда ике томлык «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н чыгаруы фән-мәдәният тормышы өчен тагын бер зур вакыйга була. Аның әһәмияте шунда: һәр фразеологик берәмлекнең мәгънәсе аңлатылып бирелә һәм мисаллар белән дәлилләнә. Сүзлектә бик борынгыдан килә торган фразеологик байлык киләчәк буыннар өчен дә беркетелеп калган, шулай ук милли фразеология зур урын алган.

2001 нче елда Ф.С. Сафиуллина бастырып чыгарган «Татарча-русча фразеологик сүзлек» бүгенге көннең иң популяр фразеологик сүзлеге дип санала. Анда татар фразеологизмнары, нигездә, эквивалент рус фразеологизмнары белән бирелә. Н. Исәнбәт сүзлегеннән аермалы буларак, бу сүзлектә рус теленнән калька буларак кергән фразеологизмнар да урын алган.

Автор аларны 40 елдан артык Казан университетында укыту һәм шул еллар дәвамында татар әдәбиятының русчага һәм рус әдәбиятының татарчага тәрҗемәләреннән, вакытлы матбугаттан, матур әдәбияттан, төрле сүзлекләрдән, җанлый сөйләмнән туплый.

Сүзлектә 16 меңнән артык фразеологик берәмлек русчага эквивалентлары белән, аерым очракларда тәрҗемә итеп бирелә. Кайбер очракларда мәгънәләр сүзгә-сүз тәрҗемә итеп тә, аерым сүзләр белән дә кхрсәтелә.

Тел материалының күпчелек өлешен фигыль фразеологизмнары тәшкил итә. Алар исем фигыль формасында (-у/-ү) бирелә. Исемнәр – баш килештә, сыйфат һәм рәвешләр – төп дәрәҗәдә, катып калган формалар – шул ук рәвештә, таркалмый торган сүзләртезмәләре актив кулланылыш формасында күрсәтелә.

Фразеологик материал һәр ике телдә мөмкин булган очракларда синонимик оялар буларак китерелгән. Татарча баганада синонимик оя булмаган очракларда русча өлешендә мөмкин булган синонимнар теркәлгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, фразеологик әйтелмәләр дөнья телләренең һәркайсында да булганга күрә, аларда уртак үзенчәлекләр һәм типологик күренешләр, әлбәттә, бар, шуның өстенә тагын һәрбер тел үзенә бер милли культура күренеше һәм система булганга күрә, һәркайсының фразеологик байлыгын, алымнарын, аның милли үзенчәлекләрен һәм шулар аша аның гомумкешелек культурасына керткән өлешләрен ачыклау кебек мөһим мәсьәләләр алга килеп баса. Моның өчен һәр телнең үз эчендә аларны туплау, барлау һәм махсус өйрәнүләр таләп ителә.

**Әдәбият**


1. Ахунҗанов Г.Х. Татар теленең идиомалары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. – 119 б.
2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 174 б.
3. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.